| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**26.02.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 493** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2024 елның 23 октябрендәге 3977 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнарны 2025 елга өстәмә индексацияләү турында» 2025 елның 07 февралендәге 5600-МР номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасында мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын финанслауның норматив принцибын гамәлгә ашыру буенча методик ярдәм күрсәтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2024 елның 23 октябрендәге 3977 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар» 1 нче кушымтасындагы «Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативы» 5 пунктын әлеге карарга кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә.
3. Әлеге карар 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru)

порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкче урынбасары- Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин

№1 кушымта.

## 5.Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативы

| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының эш сәгатьләре саны | Азык-төлеккә чыгымнар нормативы, көнгә сум/тәрбияләнүче | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомуми үсеш төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәгеләр) | | санатор төркемнәр | |
| | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып балалар бакчасына йөрүдән туктаганчыга кадәр | 2 айдан 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып балалар бакчасына йөрүдән туктаганчыга кадәр |
| 3-4 | 33,88 | 42,65 | 0 | 0 |
| 5-6 | 81,28 | 102,39 | 0 | 0 |
| 7-12 | 135,49 | 170,64 | 175,78 | 234,39 |
| 24 | 169,34 | 210,66 | 219,73 | 289,36 |